## Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

### Гражданнарның сәламәтлеген саклау турында

Әлеге Закон гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә мөнәсәбәтләрен җайга сала, медик-социаль ярдәмне гамәлгә ашыруның гарантияләрен, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренең хокукларын, социаль яклануларын, шулай ук гражданнарның гомеренә яисә сәламәтлегенә зыян китергән өчен җаваплылык билгели.

Әлеге Законның максаты Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклауны оештырудан гыйбарәт.

## I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

### 1 статья. Гражданнарның сәламәтлеген саклау

Гражданнарның сәламәтлеген саклау — һәр кешенең физик һәм психик сәламәтлеген саклап калуга һәм ныгытуга, актив тормышын озайтуга ярдәм итүгә, сәламәтлеген югалтканда аңа медик-социаль булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән икътисадый, хокукый, социаль, мәдәни, фәнни, медик-санитар характердагы чаралар бергәлеге ул.

2 статья. Гражданнарның сәламәтлеген саклауның төп принциплары

Гражданнарның сәламәтлеген саклауның төп принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) сәламәтлек саклау өлкәсендә кеше һәм граждан хокукларын саклаудан һәм әлеге хокукларга бәйле дәүләт гарантияләрен тәэмин итүдән;

2) гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә профилактика, санитария-эпидемиология һәм экология чараларының өстенлегеннән;

3) медицина, дару һәм медик-социаль ярдәмнең төп төрләрен һәм оештыру рәвешләрен һәркем файдаланырлык булудан һәм аларның гарантиялелегеннән;

4) амбулатор-поликлиник, стационар һәм шифаханә медицина ярдәме күрсәтүнең комплекслылыгыннан һәм эзлеклелегеннән;

5) сәламәтлекләрен югалтканда гражданнарның социаль якланганлыгыннан;

6) гражданнарга физик тәрбия һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудырудан;

7) сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын тәэмин итү өчен дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, милек рәвешләренә карамастан, оешмаларның, урындагы затларның җаваплылыгыннан.

3 статья. Сәламәтлекләрен саклау өлкәсендә гражданнарга дәүләт гарантияләре

Дәүләт гражданнарга Татарстан Республикасының республика бюджеты, җирле бюджетлар, мәҗбүри медицина иминлеге акчалары һәм башка чыганаклар исәбеннән дәүләт программаларында

билгеләнгән күләм чикләрендә һәм шартларда сыйфатлы медицина ярдәме күрсәтелүне һәм дару белән тәэмин ителүне гарантияли.

Дәүләт гарантияләре Татарстан Республикасы гражданнарына мәҗбүри медицина иминлеге һәм гражданнарга медицина хезмәте күрсәтү буенча дәүләт программалары нигезендә бушлай медицина ярдәме күрсәтүне күз алдында тота.

Гражданнар иминлек һәм гигиена таләпләренә җавап бирерлек эш шартларына, буш вакыттан нәтиҗәле файдалану өчен шартлар тудырылуга, билгеләнгән стандартларга туры килерлек медицина, дару, медик-социаль һәм шифаханә-савыктыру ярдәмнәре күрсәтелүгә хокуклы.

4 статья. Гражданнарның сәламәтлеген саклау турындагы законнар

Гражданнарның сәламәтлеген саклау турындагы законнар әлеге Законнан һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка законнардан һәм норматив хокукый актлардан гыйбарәт.

5 статья. Гражданнарның сәламәтлеген саклау турында Татарстан Республикасы законнарының бурычлары

Гражданнарның сәламәтлеген саклау турында Татарстан Республикасы законнарының бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә дәүләт хакимияте һәм идарәсенең республика һәм җирле органнары, җирле үзидарә органнары компетенциясен билгеләүдән;

2) юридик зат барлыкка китермичә генә эшкуарлык белән шөгыльләнүче затлар эшчәнлеген, милек рәвешләренә карамастан, оешмалар эшчәнлеген, шулай ук сәламәтлек саклауның дәүләт һәм

хосусый системалары эшчәнлеген гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә хокукый җайга салудан;

3) сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның, халыкның аерым төркемнәренең хокукларын һәм аларны үтәү гарантияләрен билгеләүдән;

4) медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренең һөнәри хокукларын, вазыйфаларын һәм җаваплылыгын, аларны социаль яклауның гарантияләрен билгеләүдән.

## II бүлек. Гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының компетенциясе

### 6 статья. Гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының компетенциясе

Гражданнарның сәламәтлеген саклау мәсьәләләрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагына түбәндәгеләр керә:

1) гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын кабул итү, үзгәртү һәм аларның үтәлешен тикшереп тору;

2) гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт сәясәтен билгеләү;

3) сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләрне карау;

4) сәламәтлек саклауга Татарстан Республикасының республика бюджетының чыгымнары өлешен раслау;

5) гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә иң мөһим республика программаларын раслау.

Гражданнарның сәламәтлеген саклау мәсьәләләрендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

1) гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә агымдагы һәм перспектив дәүләт программаларын әзерләү, гамәлгә ашыру, аларны тормышка ашыру чараларын күрү һәм аларның үтәлеше хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына хисап бирү;

2) сәламәтлек саклауга Татарстан Республикасы республика бюджетының чыгымнары өлешен билгеләү;

3) сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын, ирекен һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне тәэмин итү чараларын әзерләү һәм гамәлгә ашыру;

4) Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау;

5) медицина ярдәменең сыйфат стандартлары үтәлешен тикшереп тору чараларын күрү;

6) медицина һәм фармацевтика эшчәнлеге башкаручы субъектларны аккредитацияләү, лицензияләү һәм сертификацияләү тәртибен законнар нигезендә билгеләү;

7) гадәттән тыш хәлләр килеп туганда кешеләрнең гомерен саклап калуга һәм аларның сәламәтлеген яклауга юнәлдерелгән чараларны җайга салу, гражданнарны мондый шартлардагы гамәлләргә әзерләү;

8) Татарстан Республикасы территориясендә даруларны һәм медицина әйберләрен читтән кертү һәм читкә чыгару тәртибен билгеләү;

9) гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә фәнни тикшеренүләрне җайга салу һәм финанслау;

10) гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек.

7 статья. Дәүләт хакимияте һәм идарәсе җирле органнарының, җирле үзидарә органнарының компетенциясе

Гражданнарның сәламәтлеген саклау мәсьәләләрендә дәүләт хакимияте җирле органнарының карамагына түбәндәгеләр керә:

1) гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә законнарның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

2) җирле бюджетның сәламәтлек саклауга чыгымнарын карау һәм раслау;

3) гражданнарның сәламәтлеген саклауга билгеләнгән максатчыл фондлар оештыру турында карар кабул итү.

Гражданнарның сәламәтлеген саклау мәсьәләләрендә җирле администрацияләр карамагына түбәндәгеләр керә:

1) сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын һәм ирекген яклау;

2) сәламәтлек саклауның коммуналь системасы идарәсе схемаларын раслау, сәламәтлек саклау учреждениеләре челтәрен үстерү, аларның эшчәнлек характерын һәм күләмен ачыклау; сәламәтлек саклауның хосусый системасы үсеше өчен шартлар тудыру; башлангыч медик-санитар ярдәмне, медик-социаль ярдәмнең башка төрләрен оештыру, алардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү, медицина ярдәмен күрсәтүдә сыйфат стандартлары үтәлешен тикшереп тору; үз карамагындагы территориядә гражданнарны дарулар һәм медицина әйберләре белән тәэмин итү;

3) сәламәтлек саклауның дәүләт системасына караган оешмаларның эшчәнлеген үз вәкаләтләре чикләрендә җайга салу һәм тикшереп тору, сәламәтлекне саклауның хосусый системасында күрсәтелүче медик-социаль ярдәмнең сыйфатын тикшереп тору;

4) мәҗбүри медицина иминлеге гамәлләрен тормышка ашыру;

5) экология һәм санитария-эпидемиология хәвефсезлеген тәэмин итү, һәлакәтләр һәм табигый афәтләрдән соң килгән зыянны бетерү буенча чаралар әзерләү һәм аларны гамәлгә ашыру;

6) инвалидларны һәм психикасы какшаган затларны реабилитацияләү өчен оешмаларның эшчәнлеген тәэмин итү, аларны укытуны, яңа һөнәргә өйрәтүне һәм эшкә урнаштыруны оештыру, халыкның шушы төркемнәре өчен махсуслаштырылган предприятиеләр, цехлар, җитештерүнең башка төрләрен оештыру, шулай ук дәвалап булмый торган авырулар өчен махсус учреждениеләр булдыру;

7) халыкка һәрдаим, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша, социаль әһәмияткә ия булган йогынтылы һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыручы чирләрнең таралышы турында хәбәр итеп тору;

8) гаиләне, ата-аналарны һәм балаларны саклау;

9) гражданнарга санитария-гигиена белеме бирү.

Гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә җирле үзидарә органнары карамагына халыкның сәламәтлеген саклау буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү керә.

8 статья. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы компетенциясе

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә Татарстан Республикасында сәламәтлек саклау тармак җитәкчелеген гамәлгә ашыручы дәүләт идарәсе органы булып тора.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

— сәламәтлек саклауны үстерү, авыруларны кисәтү, медицина ярдәме күрсәтү, гражданнарны дарулар, медицина техникасы һәм медицина әйберләре белән тәэмин итү буенча республика программаларын тормышка ашырудан;

— гражданнарга күрсәтелә торган медицина ярдәменең, читтән кертелә торган медицина һәм фармацевтика продукциясенең сыйфатын, сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын һәм ирегеН яклау чараларының үтәлешен тикшереп торудан;

— медицина кадрларын һәм сәламәтлек саклау системасында башка белгечләрне әзерләүдән, яңа һөнәргә өйрәтүдән;

— медицина һәм фармацевтика эшчәнлегендә лицензияләүне һәм сертификацияләүне оештырудан;

— сәламәтлек саклау өлкәсендә нормативлар һәм стандартлар үтәлешен тикшереп торудан;

— ата-аналарның һәм баланың сәламәтлеген саклауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар әзерләүдән;

— Татарстан Республикасының дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте органнары белән берлектә гражданнарның социаль-гигиена һәм эпидемиология хәвефсезлеген тәэмин итүдә катнашудан.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы халыкның сәламәтлек торышын бәяли, аңа ярдәм итү һәм аны яхшырту өчен кирәкле чаралар исемлеген әзерли, әзерләнгән гамәлләргә икътисадый бәя бирә, гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салучы закон актларын камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертә.

## Ш бүлек. Гражданнарның сәламәтлеген саклауны оештыру

### 9 статья. Гражданнарның сәламәтлеген саклауны финанслау

Гражданнарның сәламәтлеген саклауны финанслау чыганаклары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

— Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар акчаларыннан;

— мәҗбүри һәм ирекле медицина иминләштерүенә юнәлдерелә торган акчалардан;

— дәүләт оешмаларының, җәмәгать берләшмәләренең һәм башка хуҗалык итүче субъектларның акчаларыннан;

— гражданнарның һәм оешмаларның бушлай һәм (яисә) хәйрия кертемнәреннән, иганәләреннән;

— дәүләтнең бюджеттан тыш һәм башка фондлары акчаларыннан;

— банкларның һәм башка кредиторларның кредитларыннан;

— законнар белән тыелмаган башка чыганаклардан.

<u>10 статья.</u> Халыкның санитария-эпидемиология хәвефсезлеге

Халыкның санитария-эпидемиология хәвефсезлеге дәүләт идарәсе органнары, оешмалар, җәмәгать берләшмәләре һәм гражданнар тарафыннан гигиена чаралары күрү һәм эпидемиягә каршы гамәлләр уздыру, юридик затларның һәм гражданнарның санитария кагыйдәләрен, нормаларын һәм гигиена нормативларын үтәү белән икътисадый кызыксынулары; дәүләт санитария-эпидемиология күзәтчелеге системасы, профилактика чараларын үткәрү, шул исәптән медицина белеме бирү, иммунизация һәм вакцинация үткәрү, халыкны гомуми тикшерү, шулай ук башка оештыру, хокукый һәм икътисадый гамәлләр комплексы белән тәэмин ителә.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары әйләнә-тирә мохитне саклауны оештыруны, хезмәт, көнкүреш, ял итү өчен уңайлы шартлар тудыруны, сыйфатлы туклану продуктларын, эчәр су җитештерүне, чит ил продуктларына һәм сәнәгать товарларына катгый санитария контролен тәэмин итәргә тиеш.

Алкоголь эчемлекләрне һәм тәмәке әйберләрен сатучы оешмалар мәктәпкәчә балалар учреждениеләре һәм гомуми белем бирү учреждениеләре территориясендә һәм аларга якын урнашмаска тиеш.

11 статья. Сәламәтлек саклауның дәүләт системасы

Сәламәтлек саклауның дәүләт системасына мөлкәтләре дәүләт милкендә булган сәламәтлек саклау идарәсе органнары, медицина, даруханә учреждениеләре һәм сәламәтлек саклауның башка оешмалары керә.

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклауның дәүләт системасы республика һәм коммуналь сәламәтлек саклау системасыннан гыйбарәт.

Сәламәтлек саклауның республика системасына үз компетенциясе чикләрендә сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, республика программаларын үтәү һәм медицина фәнен үстерү буенча чаралар планлаштыручы һәм аларны тормышка ашыручы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтчелеге дәүләт комитеты, шулай ук мөлкәтләре дәүләт милкендә булган медицина, фәнни-тикшеренү, санитария-профилактика, даруханә оешмалары, медицина белеме бирү учреждениеләре, суд—медицина экспертизасы учреждениеләре, матди-техник тәэминат хезмәтләре, медицина препаратлары һәм медицина техникасы житештерүче предприятиеләр һәм башка оешмалар керә.

Сәламәтлек саклауның системасына дәүләт сәламәтлек саклауның дәүләт идарәсе жирле органнары һәм мөлкәтләре коммуналь милектә булган медицина, фармацевтика һәм даруханә оешмалары керә.

Сәламәтлек саклауның дәүләт идарәсе органнары халыкка санитария-гигиена белеме бирү өчен, медик-социаль ярдәмнең гарантияләнгән күләме белән халыкны тәэмин итү, үз карамагындагы

территориядә сәламәтлек саклауның коммуналь системасын үстерү өчен җаваплы булалар, сәламәтлек саклауның коммуналь һәм хосусый системасы оешмалары тарафыннан медик-социаль һәм дарулар белән ярдәм күрсәтелүнең сыйфатын тикшереп торалар.

Сәламәтлек саклауның коммуналь системасы оешмалары эшчәнлеге җирле бюджетлар, шулай ук Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары, гражданнарның сәламәтлеген саклау өчен билгеләнгән медицина иминиятенә иминлек кертемнәре һәм максатчыл фондлар, законнар белән тыелмаган бүтән чыганаклар исәбеннән финанслана.

12 статья. Сәламәтлек саклауның хосусый системасы

Мөлкәтләре хосусый милектә булган медицина, даруханә, фәнни-тикшеренү оешмалары, медицина белеме бирү учреждениеләре һәм сәламәтлек саклауның башка оешмалары, шулай ук хосусый медицина һәм фармацевтика эшчәнлеге белән шөгыльләнүче затлар сәламәтлек саклауның хосусый системасын тәшкил итәләр.

Сәламәтлек саклауның хосусый системасы оешмалары һәм хосусый медицина һәм фармацевтика эшчәнлеге белән шөгыльләнүче затлар законнар нигезендә теркәлергә тиеш.

Сәламәтлек саклауның хосусый системасы оешмалары һәм хосусый медицина һәм фармацевтика белән шөгыльләнүче затлар эшчәнлеге законнар нигезендә башкарыла.

Чит илләрнең физик һәм юридик затлары Татарстан Республикасында законнар нигезендә хосусый медицина оешмалары төзергә хокуклы.

13 статья. Медицина һәм фармацевтика эшчәнлегенең билгеле бер төрен аккредитацияләү һәм аларга лицензияләр бирү тәртибе һәм шартлары

Сәламәтлек саклауның дәүләт һәм хосусый системалары оешмалары, хосусый медицина һәм фармацевтика белән шөгыльләнүче затлар Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлекләрен бары тик үзләре сайлап алган эшчәнлек төренә лицензия булганда гына башкара алалар.

Сәламәтлек саклауның дәүләт һәм хосусый системасы оешмалары, шулай ук хосусый медицина һәм фармацевтика эшчәнлеге белән шөгыльләнүче затлар лицензияне сертификат нигезендә алалар. Берничә юнәлеш буенча медицина ярдәме күрсәткән очракта лицензиядә эшчәнлекнең һәр төре күрсәтелә.

Лицензияләр һәм сертификатлар бирү медицина һәм фармацевтика эшчәнлеген аккредитацияләү һәм лицензияләү буенча вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан законнар нигезендә башкарыла.

Медицина һәм фармацевтика эшчәнлеген аккредитацияләү һәм лицензияләү буенча дәүләт органы турындагы нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

Медицина һәм фармацевтика эшчәнлеген аккредитацияләү һәм лицензияләү буенча вәкаләтле дәүләт органы карарына карата аккредитацияләү һәм лицензияләү субъектлары тарафыннан суд тәртибендә законнар нигезендә шикаять белдерелергә мөмкин.

Медицина һәм фармацевтика эшчәнлеген дәүләт аккредитацияләве һәм лицензияләвенең элек гамәлдә булган тәртибе нигезендә сәламәтлек саклауның дәүләт, хосусый системалары оешмаларына, хосусый медицина һәм фармацевтика эшчәнлеге белән шөгыльләнүче затларга бирелгән лицензияләр һәм сертификатлар алар бирелгән вакыт беткәнче генә гамәлдә булалар.

14 статья. Сәламәтлек саклау системасында әхлак мәсьәләләре комитетлары (комиссияләре)

Сәламәтлек саклауның дәүләт системасы оешмаларында кеше һәм гражданнарның аерым төркемнәре хокукларын яклау максатларында медицина әхлагы нормаларын әзерләүдә һәм аларны бозуга бәйле мәсьәләләрне хәл итүдә, гамәли һәм фәнни-тикшеренү эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләре буенча тәкъдимнәр әзерләүдә катнашу өчен һәм гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә башка мәсьәләләрне хәл итү өчен әхлак мәсьәләләре буенча иҗтимагый комитетлар (комиссияләр) төзелергә мөмкин.

Сәламәтлек саклау системасында әхлак мәсьәләләре комитетлары (комиссияләре) составына җәмәгатьчелек мәнфәгатьләрен чагылдыручы затлар (медицина этикасы белгечләре, юристлар, фән һәм сәнгать эшлеклеләре, дин әһелләре, медицина җәмәгать берләшмәләре һәм һөнәр берлекләре вәкилләре) керә.

Сәламәтлек саклау системасында әхлак мәсьәләләре комитетларын (комиссияләрен) төзү һәм аларның эшчәнлеге тәртибе турындагы нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

IV бүлек. Сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның хокуклары һәм бурычлары

15 статья. Татарстан Республикасы гражданнарының сәламәтлек саклауга хокукы

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасының һәр гражданы, чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә, расасына, милләтенә, женесенә, белеменә, теленә, сәяси карашларына, дини мәсләгенә, шөгыленең төренә һәм рәвешенә, яшәү

урынына һәм башкаларга карамастан, сәламәтлек саклау, шул исәптән медицина ярдәмен алу хокукына ия була.

Әлеге хокук әйләнә-тирә табигать мохитен саклау, гражданнарга хезмәттә, көнкүрештә, ял итүдә, тәрбия һәм белем бирүдә уңайлы шартлар тудыру, яхшы сыйфатлы азык-төлек продуктлары җитештерү һәм сату белән, шулай ук гражданнарга медик-социаль ярдәмнән файдалану мөмкинлеге бирү белән тәэмин ителә.

Татарстан Республикасы үз гражданнарына нинди дә булса чир аркасында дискриминацияләүнең төрле рәвешләреннән яклануны гарантияли. Әлеге нигезләмәне бозуда гаепле затлар законда билгеләнгән җаваплылыкка тартылалар.

16 статья. Сәламәтлеккә йогынты ясаучы факторлар турында гражданнарның мәгълүмат алу хокукы

Татарстан Республикасы гражданнары сәламәтлек саклауга булышлык итүче яисә аңа зарарлы йогынты ясаучы факторлар, шул исәптән үзе яшәгән районның санитария-эпидемиология торышы турында, рациональ туклану нормалары, азык-төлек, эшләр, хезмәт күрсәтүләр, аларның санитар нормаларга туры килүе һәм башка факторлар турында үз вакытында һәм дөрес мәгълүмат алырга хаклы.

Сәламәтлек саклау системасында гамәлдә булган мәгълүмат, дәүләт, табиблык яисә коммерция серен тәшкил иткәннәреннән гайре, гражданнарга массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр ителергә һәм үтенечләре буенча гражданнарга, сәламәтлек саклау системасы берләшмәләренә, оешмаларына файдаланырлык булырга тиеш.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтчелеге дәүләт комитеты гражданнарның сәламәтлекләрен саклау буенча барлык субъектлар бирергә тиешле мәгълүматларның күләмен һәм кабатлану чорын билгели, шулай ук сәламәтлек саклау оешмаларының

үзара алмашып торырга тиешле мәгълүмат күләмен килештерә; Татарстан Республикасының гражданнарның сәламәтлекләрен саклау системасы турындагы хәбәрләрне үз эченә алган мәгълүматлар базасын төзүне һәм алардан файдалану шартларын килештерә.

Медикаментларны, медицина әйберләрен, медицина техникасын, шулай ук дәвалау алымнарын, профилактика, диагностика һәм савыктыруны рекламалау законнарда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Әлеге статьяны бозган өчен законда билгеләнгән җаваплылык карала.

17 статья. Гражданнарның медик-социаль ярдәм алу хокукы

Авырып киткәндә, хезмәткә сәләтен югалтканда һәм башка очракларда Татарстан Республикасы гражданнары медик-социаль ярдәм алырга хаклы, ә моңа профилактика, дәвалау-диагностика, савыктыру, протез-ортопедия һәм теш протезы ярдәмнәре, шулай ук авыруларны, хезмәткә сәләтсезләрне һәм инвалидларны карау буенча, вакытлыча хезмәт сәләтен югалтканда пособие түләүне дә кертеп, социаль ярдәм чаралары керә.

Медик-социаль ярдәм сәламәтлек саклауның дәүләт һәм хосусый системасы оешмаларында, шулай ук халыкны социаль яклау системасы учреждениеләрендә медицина, социаль хезмәткәрләр һәм башка белгечләр тарафыннан күрсәтелә.

Сәламәтлек саклауның дәүләт һәм башка оешмаларында гражданнар законнар нигезендә түләүсез медицина ярдәме алырга хаклы.

Гражданнар ирекле медицина иминләштерүе программалары нигезендә, шулай ук закон белән тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән өстәмә медицина хезмәте һәм башка хезмәт күрсәтелүләргә хаклы. Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау оешмаларында

түләүле медицина ярдәме күрсәтү кагыйдәләре Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

Гражданнар протезлар, ортопедия-төзәтү җайланмалары, колак аппаратлары, йөрү җайланмалары һәм башка махсус чаралар белән ташламалы тәэмин ителергә хокуклы. Әлеге хокукка ия булган гражданнарның категорияләрен, шулай ук аларны протез-ортопедия һәм теш протезы ярдәме белән ташламалы тәэмин итү шартларын һәм тәртибен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты законнар нигезендә билгели.

Гражданнар медицина экспертизасыннан, шул исәптән шәхси гариза буенча махсус оешмаларда башкарылучы бәйсез экспертизадан әлеге Законның 51 статьясы нигезендә файдалану хокукына ия.

Физик тәрбия белән шөгыльләнүче балалар, яшүсмерләр, укучылар, инвалидлар һәм пенсионерлар түләүсез медицина контроле хокукына ия булалар.

Эшләүче гражданнар тирә-юньдәге кешеләрнең йогышлы чир белән авырулары аркасындагы карантин вакытында санитария-эпидемиология хезмәте тарафыннан эштән читләштерелгән очракта пособие алу хокукына ия булалар. Әгәр балигъ булмаган яисә законда билгеләнгән тәртиптә хезмәткә сәләтсез дип танылган гражданнар карантинда булса, пособие ата-ананың берсенә (законлы вәкилгә) яисә гаиләнең башка әгъзасына законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелә.

<u>18 статья.</u> Чит ил гражданнарының, гражданлыксыз затларның һәм качакларның сәламәтлек саклауга хокукы

Татарстан Республикасы территориясендәге чит ил гражданнарына Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре нигезендә сәламәтлек саклауга хокук гарантияләнә.

Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче гражданлыксыз затларга һәм качакларга, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләрендә башкасы каралмаган булса, сәламәтлек саклау хокукы Татарстан Республикасы гражданнары белән бертигез дәрәҗәдә гарантияләнә.

Чит ил гражданнарына, гражданлыксыз затларга һәм качакларга медицина ярдәме күрсәтү тәртибе законнар белән билгеләнә.

19 статья. Гражданнарның бурычлары

Дәүләт гражданнарның сәламәтлекләрен ныгытырлык, физик тәрбия һәм спорт үсешенә ярдәм итәрлек эшчәнлекне хуплый.

Гражданнар үз сәламәтлекләрен кайгыртырга тиешләр.

20 статья. Һөнәр эшчәнлегенең аерым төрләре белән шөгыльләнүче гражданнарның сәламәтлеген саклау

Гражданнарның сәламәтлеген саклау йөзеннән, йогышлы һәм һөнәри авыруларны кисәтү максатларында кайбер һөнәрләр, житештерүләр, оешмалар хезмәткәрләре (исемлеген законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслый) эшкә урнашканда мәҗбүри башлангыч һәм аннан соңгы даими (21 яшькә кадәрге затларга — ел саен) медицина тикшерүләре үтәләр.

Граждан сәламәтлек торышы буенча хезмәт эшчәнлегенең һәм хәвеф-хәтәр чыганагы белән бәйле эшчәнлекнең кайбер төрләрен үтәүгә вакытлыча (биш елдан да артмаган чорга һәм алга таба яңадан таныклану хокукы белән) яисә даими рәвештә яраксыз дип танылырга мөмкин. Мондый карар белгеч-профпатолог һәм медик-социаль экспертиза бәяләмәсе буенча медицина кирәкми дип тапкан күрсәткечләр исемлеге нигезендә кабул ителә, һәм аңа суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

һөнәр эшчәнлегенең һәм хәвеф-хәтәр чыганагы белән бәйле эшчәнлекнең кайбер төрләрен башкару өчен медицина кирәкми дип тапкан күрсәткечләр исемлеге законнар белән билгеләнә.

Законнарда каралган очракларда эш бирүче предприятие хезмәткәрләрен алдан (эшкә урнашканда) һәм даими (хезмәт эшчәнлеге дәвамында) медицина тикшерүләре үткәрергә тиеш. Хезмәткәрләрне медицина тикшерүләре эш бирүче исәбеннән үткәрелә.

## V бүлек. Сәламәтлек саклау өлкәсендә аерым төркем гражданнарның хокуклары

21 статья. Гаилә хокуклары

Һәр граждан киләчәк буында ихтимал булган нәсел чирләрен кисәтү максатында медицина күрсәткечләре буенча гаиләне планлаштыру, социаль билгеләнешле һәм социаль шартларга бәйле авырулар, әйләнә-тирә өчен куркыныч тудыручы авырулар барлыгы турындагы мәсьәләләр, гаилә-никах мөнәсәбәтләренең медик-психологик аспектлары буенча сәламәтлек саклауның дәүләт системасы оешмаларында түләүсез консультацияләр, шулай ук медик-генетик һәм башка консультацияләр алырга һәм тикшерүләр узарга хаклы.

Гаилә аның бергә яшәүче барлык балигъ булган әгъзалары килешүе нигезендә ана яшәү урыны буенча медицина ярдәмен тәэмин итүче гаилә табибын сайларга хаклы. Балалы гаиләләр (беренче чиратта тулы булмаган гаиләләр, инвалид балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм балаларны тәрбияләүче гаиләләр) гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә законнарда билгеләнгән өстенлекле ташламалардан файдалану хокукына ия.

Ата-ананың берәрсенә яисә ата-ана теләге буенча гаиләнең башка әгъзасына баланы дәвалау мәнфәгатьләрендә бала медицина

учреждениесендә булган барлык дәвердә, бала ничә яшьтә булуга карамастан, бала белән бергә булу хокукы бирелә.

Карантин вакытында авыру баланы караган өчен пособиеләр түләү тәртибе законнар белән билгеләнә.

22 статья. Йөкле хатыннарның һәм аналарның хокуклары

Дәүләт йөкле хатыннарга, аларның физиологик үзенчәлекләренә һәм сәламәтлек торышына җавап бирерлек шартларда эшләү хокукын тәэмин итә.

Һәр хатын-кыз йөклелек чорында, бала табу вакытында һәм бала тапканнан соң сәламәтлек саклауның дәүләт системасы оешмаларында гражданнарның сәламәтлеген саклау өчен билгеләнгән максатчыл фондлар исәбеннән, шулай ук закон белән тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән махсус медицина ярдәме белән тәэмин ителә.

Хатыннар йөкле вакытта һәм бала туганнан соң, шулай ук 15 яшькә кадәрге авыру баланы караган өчен законда билгеләнгән тәртиптә пособие һәм бала тәрбияләү өчен түләүле ял алырга хаклы.

Йөклелек һәм бала табу буенча түләүле ялның гарантияләнгән чоры закон белән билгеләнә.

Дәүләт йөкле хатыннарга, бала имезүче аналарга, шулай ук өч яшькә кадәрге балаларга тиешле тукלануны, шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә махсус туклану пунктлары һәм кибетләре аша, кирәк очракта табиблар бәяләмәсе буенча, азык-төлек белән тәэмин ителүне дә гарантияли.

23 статья. Балигъ булмаганнарның хокуклары

Үз сәламәтлекләрен саклау мәнфәгатьләрендә балигъ булмаганнар түбәндәге хокукларга ия:

1) Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә балаларга, яшүсмерләргә хезмәт күрсәтү урыннарында диспансер күзәтүе узу һәм дәвалану;

2) Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән ташламалы шартларда Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән медик-социаль ярдәм алу һәм туклану;

3) физиологик үзенчәлекләренә һәм сәламәтлек торышына туры килерлек һәм тискәре йогынты ясарлык факторлардан азат булган шартларда санитария-гигиена белеме алу, уку һәм хезмәт;

4) һөнәри яраклылык билгеләнгәндә Татарстан Республикасынын республика бюджеты һәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән түләүсез медицина консультациясе алу;

5) үзләренә аңлаешлы рәвештә сәламәтлек торышы хакында кирәкле мәгълүмат алу.

15 яшьтән өлкәнрәк балигъ булмаганнар медицина катышына тиешле мәгълүмат алганнан соң ихтыярый ризалык бирергә яисә әлеге Законның 31, 32, 33 статьялары нигезендә аны кире кагарга хаклы.

Физик яисә психик кимчелекле балигъ булмаганнар ата-аналары яисә аларны алыштыручы затлар гаризасы буенча Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлар, хәйрия һәм башка фондлар, шулай ук ата-аналар яисә аларны алыштыручы затлар акчалары исәбеннән социаль яклау системасы учреждениеләрендә тотылырга мөмкин.

24 статья. Хәрби хезмәткәрләрнең, хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле һәм контракт нигезендә хәрби хезмәткә алынучы гражданнарның хокуклары

Хәрби хезмәткәрләр, хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле һәм контракт буенча хәрби хезмәткә алынучы гражданнар законнар нигезендә сәламәтлекләрен саклауга хокуклы.

25 статья. Өлкән яшьтәге гражданнарның хокуклары

Өлкән яшьтәге гражданнарга (картлык буенча пенсия билгеләү өчен закон белән күрсәтелгән яшькә җиткәннәргә) медик-социаль ярдәм аларда булган авыруларны дәвалауга, аларны карауга, актив яшәүләренә ярдәм итүгә һәм авырган, үзләренең яшәү ихтыяжларын канәгатьләндерә алмаган очракта социаль яклауга юнәлдерелә.

Өлкән яшьтәге гражданнар медицина бәяләмәсе нигезендә шифаханә-ял йортларында түләүсез яисә медицина иминләштерүе, халыкны социаль яклау органнары акчалары исәбеннән ташламалы шартларда дәвалануга һәм реабилитацияләнүгә хокуклы.

26 статья. Инвалидларның хокуклары

Инвалидлар, шул исәптән инвалид балалар һәм балачактан инвалидлар закон нигезендә ташламалы шартларда медик-социаль ярдәмгә, реабилитацияләнүгә, дарулар һәм протезлар, протез-ортопедия әйберләре, колак аппаратлары, күзлекләр, йөрү җайланмалары белән тәэмин ителүгә, шулай ук һөнәри әзерлеккә, яңа һөнәр өйрәнүгә хаклы.

Хезмәткә сәләтсез инвалидлар сәламәтлек саклауның дәүләт системасы оешмаларында медик-социаль ярдәм алуга, өйдә каралуга, үзенең төп яшәү ихтыяжларын канәгатьләндерә алмаган очракта халыкны социаль яклау системасы учреждениеләрендә тотылуга хаклы.

Инвалидларга медик-социаль ярдәм күрсәтү тәртибе һәм аларга өстенлекле ташламалар исемлеге закон белән билгеләнә.

Инвалид балаларны һәм балачактан инвалидларны 18 яшькә җиткәнче карау өчен эшләүче ата-аналарның берәрсенә (законлы вәкилгә) закон нигезендә айга дүрт түләүле өстәмә ял көне бирелә, бу көннәрдән күрсәтелгән затларның берәрсе яисә килешү буенча үзара бүлешеп файдаланырга мөмкин.

27 статья. Гадәттән тыш вәзгыятьләр вакытында һәм экологик уңайсыз районнарда гражданнарның хокуклары

Гадәттән тыш вәзгыять вакытында зыян күргән гражданнар түләүсез медицина ярдәме, шифаханә-ял йорты һәм савыктыру дәвалары алырга, гадәттән тыш вәзгыятьтән соңгы нәтиҗәләрне ачыклау һәм гомерләренә, сәламәтлекләренә хәвеф-хәтәрне киметү буенча гигиена чаралары һәм эпидемиягә каршы гамәлләр үткәрергә хаклы.

Законда билгеләнгән тәртиптә экологик уңайсыз дип танылган районнарда яшәүче Татарстан Республикасы гражданнарына бушлай медицина ярдәме, өйләнешкәндә медик-генетик һәм башка консультацияләр, тикшеренүләр, шулай ук ташламалы шартларда шифаханә-ял йорты һәм савыктыру дәвасы, дарулар, иммунобиологик препаратлар һәм башка медицина әйберләре белән тәэмин итү гарантияләнә.

Гадәттән тыш вәзгыять шартларында кешеләрне коткарганда һәм медицина ярдәме күрсәткәндә зыян күргән гражданнарга, шифаханә-ял йортларында дәвалану һәм реабилитацияләүнең барлык төрләрен дә кертеп, түләүсез дәвалану, шулай ук законда билгеләнгән тәртиптә матди компенсация гарантияләнә.

28 статья. Кулга алынган, тоткынлыкта булган, ирегеннән мәхрүм итү урыннарында утыручы яисә административ кулга алынучы затларның медицина ярдәме алуга хокуклары

Кулга алынган, тоткынлыкта булган, ирегеннән мәхрүм итү урыннарында утыручы, административ кулга алынучы затлар законнар нигезендә медицина ярдәме алырга хокуклы.

## VI бүлек. Медик-социаль ярдәм күрсәткәндә гражданнарның хокуклары

### 29 статья. Пациент хокуклары

Пациент — медицина һәм дарулар ярдәменнән файдаланучы яисә теләсә нинди медицина катышына мохтаҗ зат.

Медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать иткәндә һәм аны алганда пациент түбәндәгеләргә хокуклы:

1) медицина хезмәткәрләренең һәм хезмәт күрсәтүчеләрнең ихтирамлы һәм кешелекле мөнәсәбәтенә;

2) үз ризалыгы белән табибны, шул исәптән, аларның ризалыгын исәпкә алган килеш, гаилә табибын һәм дәвалаучы табибны сайлап алырга, шулай ук мәҗбүри һәм ирекле медицина иминләштерүе шартнамәләре нигезендә медицина оешмасын сайлап алырга;

3) санитария-гигиена таләпләренә туры килерлек шартларда тикшерелүгә, дәвалануга һәм торуга;

4) медицина ярдәме күрсәтү барышында индивидуаль мөнәсәбәткә;

5) медицина ярдәменең дәүләт тарафыннан гарантияләнгән күләменә, сыйфатына һәм үз вакытында күрсәтелүенә;

6) аның үтенече буенча консилиум һәм башка белгечләр белән консультацияләр үткәрүгә;

7) чиргә һәм (яисә) медицина катышына бәйле авыртуларны мөмкин булган ысуллар һәм чаралар белән җиңеләйтүгә;

8) медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать итү фактының, сәламәтлек торышы, диагноз турындагы һәм тикшерелү, дәвалану барышында алынган башка мәгълүматларның сер итеп саклануына;

9) тиешле мәгълүмат алганнан соң медицина катышына ихтыярый ризалык бирүгә һәм аны кире кагуга;

10) үзенең хокуклары һәм бурычлары, сәламәтлек торышы хакында тулы һәм дөрес мәгълүмат алуга;

11) мәҗбүри һәм ирекле медицина иминләштерүе программалары кысаларында медицина хезмәтләре алуга һәм башка төрле хезмәтләр күрсәтелүгә;

12) медицина ярдәме күрсәткәндә аның гомеренә яисә сәламәтлегенә китерелгән зыянны түләттерүгә;

13) медицина һәм дарулар ярдәменең сыйфатына экспертиза үткәрелүгә;

14) аның хокукларын яклау өчен адвокат яисә башка законлы вәкил бирелүгә;

15) пациент теләге буенча туганнары, медицина хезмәткәрләре, төрле конфессияләрнең дин әһелләре ягыннан рухи һәм әхлакый ярдәмгә, шул исәптән, әгәр медицина оешмаларының эчке тәртибенә каршы килмәсә, аерым бина бирелүгә;

16) медик-социаль реабилитацияләнүгә.

Пациентның хокуклары бозылган очракта, ул турыдан-туры үзенә медицина ярдәме күрсәтә торган медицина учреждениесенең җитәкчесенә яисә башка урындагы затына, тиешле медицина җәмәгать берләшмәләренә йә медицина һәм фармацевтика эшчәнлеген аккредитацияләү һәм лицензияләү буенча вәкаләтле дәүләт органына, йә судка мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

Пациент хокукларын яклау башка гражданнарның сәламәтлегенә, хокукларына һәм ирегенә зыян китермәслек булырга тиеш.

**30 статья. Гражданнарның сәламәтлек торышы турындагы мәгълүмат алу хокукы**

Һәр граждан үзенә аңлаешлы рәвештә сәламәтлеге торышы турында, тикшерү нәтиҗәләре хакындагы белешмәләрне, авыруының

барлыгын, диагнозын һәм фаразын, дәвалау алымнарын, аларга бәйле ихтимал зарарны, медицина катышының мөмкин булган вариантларын, алардан соңгы үзгәрешләрне һәм узган дәвалау нәтиҗәләрен дә кертеп, мәгълүмат алырга, дәвалаучы табибның һәм башка дәвалаучы затларның һөнәри статусы турында мәгълүмат алырга хокуклы.

Гражданның сәламәтлеге турында мәгълүмат — үзенә, ә 15 яше тулмаган һәм законда билгеләнгән тәртиптә хезмәткә сәләтсез дип танылган гражданнарның законлы вәкилләренә дәвалаучы табиб, медицина учреждениесенең бүлек мөдире яисә тикшерүдә һәм дәвалауда турыдан-туры катнашкан башка белгечләр тарафыннан бирелә.

Сәламәтлек торышы турындагы мәгълүмат гражданга аның ихтыярыннан башка бирелми. Авыру үсешенә тискәре фараз бирелгән очракларда мәгълүмат әдәпле рәвештә гражданга һәм, әгәр дә ул хәбәр итүгә каршы килмәсә һәм (яисә) мондый мәгълүмат бирелергә тиешле затны үзе билгеләмәсә, аның гаилә әгъзаларына хәбәр ителергә тиеш.

Граждан үзенең сәламәтлек торышын чагылдыручы медицина документлары белән турыдан-туры танышырга һәм аның буенча башка белгечләрдән консультацияләр алырга хокуклы. Әгәр документлар өченче як мәнфәгатьләренә кагылмаса, граждан таләбе буенча аңа сәламәтлеге торышын чагылдыручы документларның күчермәләре бирелә.

Гражданның медицина документларына кертелгән мәгълүмат табиблык серен тәшкил итә һәм граждан ризалыгыннан башка бары тик әлеге Законның 58 статьясында каралган нигезләрдә генә бирелергә мөмкин.

31 статья. Медицина катышына ризалык бирү

Гражданның алдан ук тиешле мәгълүмат алганнан соң бирелгән ихтыярый ризалыгы һәм аның медицина документациясендә рәсмиләштерелүе медицина катышы өчен кирәкле шарт булып тора.

Гражданның хәле үз ихтыярын белдерерлек булмаганда, ә медицина катышы кичектергесез кирәк очракта, граждан мәнфәгатьләрендә аны үткәрү турындагы мәсьәләне консилиум, ә консилиум җыю мөмкинлеге булмаганда, медицина учреждениесенең урындагы затларына хәбәр итеп, турыдан-туры дәвалаучы (кизү торучы) табиб хәл итә.

15 яше тулмаган затларга һәм законда билгеләнгән тәртиптә эшкә сәләтсез дип танылган гражданнарга карата медицина катышына ризалыкны, әлеге Законның 30 статьясындагы беренче өлешендә каралган белешмәләрне алганнан соң, аларның законлы вәкилләре бирә.

Законлы вәкилләр булмаганда, медицина катышы турындагы мәсьәләне — консилиум, ә консилиум җыю мөмкинлеге булмаганда, медицина учреждениесенең урындагы затларына һәм законлы вәкилләргә хәбәр итеп, турыдан-туры дәвалаучы (кизү торучы) табиб хәл итә.

32 статья. Медицина катышыннан баш тарту

Әлеге Законның 33 статьясында каралган очраклардан гайре, граждан яисә аның законлы вәкиле, медицина катышыннан баш тартырга яисә аны туктатуны таләп итәргә хокуклы.

Медицина катышыннан баш тартканда, гражданга яисә аның законлы вәкиленә аңлаешлы итеп ихтимал булган нәтиҗәләр аңлатылырга тиеш. Ихтимал булган нәтиҗәләрне күрсәтеп, медицина катышыннан баш тарту медицина документларында язмача

рәсмиләштерелә һәм граждан яисә аның законлы вәкиле, шулай ук медицина хезмәткәре тарафыннан имзалана.

15 яше тулмаган затның һәм закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә эшкә сәләтсез дип табылган гражданнарның гомерен коткару өчен кирәк булган медицина катышыннан ата-аналары (законлы вәкилләре) баш тартканда, медицина оешмалары әлеге затны опекага яисә попечительлеккә алу өчен опека һәм попечительлек органына яисә судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

33 статья. Медицина ярдәмен гражданнар ризалыгыннан башка күрсәтү

Гражданнар яисә аларның законлы вәкилләре ризалыгыннан башка медицина ярдәме (медицина тануклавы, госпитальләштерү, күзәтү һәм изоляцияләү) әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркынычлы авырулардан интегүче затларга, авыр психик авырулардан интегүче затларга яисә ижтимагый куркынычлы гамәлләр кылган затларга, законда билгеләнгән нигезләрдә һәм тәртиптә күрсәтелә. Гражданнар яисә аларның законлы вәкилләре ризалыгыннан башка медицина тануклавы һәм күзәтүе үткәрү турындагы карарны — табиб (консилиум), ә гражданнар ризалыгыннан яисә аларның законлы вәкилләре ризалыгыннан башка госпитальләштерү турындагы карарны суд кабул итә.

Эпидемиягә каршы гамәлләр уздыру белән бәйле медицина ярдәмен гражданнар яисә аларның законлы вәкилләре ризалыгыннан башка күрсәтү законда билгеләнгән тәртиптә тормышка ашырыла.

Авыр психик авырулардан интегүче затларны аларның ризалыгыннан башка тануклау һәм госпитальләштерү законда билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

Иҗтимагый куркынычлы гамәлләр кылган затларга карата законда билгеләнгән нигезләрдә һәм тәртиптә мәҗбүри рәвештә медицина чаралары кулланылырга мөмкин.

Гражданнарның медицина учреждениесендә булулары аларның ризалыгыннан башка госпитальләштерү үткәрелгән нигезләр юкка чыкканчы дәвам итә яисә суд карары белән туктатыла.

## VII бүлек. Гаиләне планлаштыру һәм кешенең репродуктив функциясен көйләү буенча медицина эшчәнлеге

34 статья. Ясалма аталандыру һәм эмбрионны имплантацияләү

Бала табу яшендәге балигъ булган һәр хатын-кыз ясалма аталандырылу һәм эмбрионны имплантацияләү хокукына ия.

Хатын-кызны ясалма аталандыру һәм эмбрионны имплантацияләү әлеге төр эшчәнлеккә лицензия алган учреждениеләрдә, ир белән хатынның (ялгыз хатын-кызның) язмача ризалыгы булганда тормышка ашырыла.

Ясалма аталандыру һәм эмбрионны имплантацияләү, шулай ук донорның шәхесе турында белешмәләр табиб серен тәшкил итәләр.

Хатын-кыз ясалма аталандыру һәм эмбрионны имплантацияләү процедурасы турында, аның нәтиҗәләренең медицина һәм хокукый аспектлары турында, медик-генетик тикшеренү белешмәләре, донорның тышкы кыяфәте һәм милләте турында медицина катышын гамәлгә ашыручы табиб бирә торган мәгълүматлар һәм белешмәләр алырга хокуклы.

Ясалма аталандыруны һәм эмбрионны имплантацияләүне законсыз башкару законда билгеләнгән җаваплылыкка китерә.

35 статья. Йөклелекне ясалма өзү

Һәр хатын-кыз ана булу-булмау мәсьәләсен мөстәкыйль хәл итәргә хокуклы. Йөклелекне хатын-кыз теләге белән ясалма өзү йөклелекнең 12 атнасына кадәр, социаль күрсәтүләр буенча — йөклелекнең 22 атнасына кадәр, ә медицина күрсәтүләре һәм хатын-кыз ризалыгы булганда, йөклелекнең күпме булуына карамастан үткәрелә.

Йөклелекне ясалма өзү эшчәнлекнең әлеге төренә лицензия алган медицина оешмаларында махсус әзерлеге булган табиблар тарафыннан үткәрелә.

Йөклелекне ясалма өзү өчен медицина күрсәтүләре исемлеге — Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан, ә социаль күрсәтүләр исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслый торган нигезләмә белән билгеләнә.

Йөклелекне ясалма өзүне законсыз башкару законда билгеләнгән җаваплылыкка китерә.

36 статья. Медицина стерильләштерүе

Кешене нәсел яңарту сәләтеннән мәхрүм итү максаты белән махсус катышу кебек яисә контрацепция ысулы буларак медицина стерильләштерүе 35тән яшьрәк булмаган яисә кимендә ике баласы булган гражданның язмача гаризасы буенча гына, ә медицина күрсәтүләре булганда һәм гражданның ризалыгы белән — яшенә һәм балалары булу-булмауга бәйсез рәвештә үткәрелергә мөмкин.

Медицина стерильләштерүе өчен медицина күрсәтүләре исемлеге Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан законнар нигезендә билгеләнә.

Медицина стерильләштерүе эшчәнлекнең әлеге төренә лицензия алган дәүләт сәламәтлек саклау системалары учреждениеләрендә үткәрелә.

Медицина стерильләштерүен законсыз үткәрү законда билгеләнгән җаваплылыкка китерә.

## VIII бүлек. Гражданнарга медик-социаль ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыру гарантияләре

### 37 статья. Беренчел медик-санитар ярдәм

Беренчел медик-санитар ярдәм һәр граждан файдаланырлык төп һәм түләүсез медицина хезмәте күрсәтү төре ул, аңа түбәндәгеләр керә: иң киң таралган авыруларны, шулай ук имгәнүләрне, агулануларны һәм башка кичектергесез халәтләрне дәвалау; санитар-гигиена гамәлләре һәм эпидемиягә каршы гамәлләр уздыру, житди авыруларга медицина профилактикасы үткәрү; санитар-гигиена белеме бирү; гаиләне, ана булуны, ата булуны һәм балалыкны саклау гамәлләләре үткәрү, яшәү урыннарында гражданнарга медик-санитар ярдәм күрсәтү белән бәйле башка гамәлләр.

Беренчел медик-санитар ярдәм сәламәтлек саклаунын коммуналь системасы һәм санитария-эпидемиология хезмәте оешмалары тарафыннан тәэмин ителә. Беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүдә шулай ук сәламәтлек саклауның республика һәм хосусый системалары оешмалары, шулай ук хосусый медицина эшчәнлеге белән шөгыльләнүче затлар да катнаша ала.

Беренчел медик-санитар ярдәмне финанслау жирле бюджет акчалары, гражданнарның сәламәтлеген саклау өчен билгеләнгән максатчыл фондлар һәм законнар белән тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

38 статья. Ашыгыч медицина ярдәме

Ашыгыч медицина ярдәме гражданнарга кичекмәстән медицина ярдәме таләп ителгән халәтләрдә (бәхетсезлек очракларында, имгәнүләр, агуланулар вакытында, башка халәтләрдә һәм бүтән авырулар вакытында) күрсәтелә, ул, нинди территориягә, нинди ведомствога керүенә һәм милек рәвешенә карамастан, медицина оешмалары, медицина хезмәткәрләре, шулай ук аны беренче ярдәм рәвешендә закон буенча яисә махсус кагыйдә буенча күрсәтергә тиешле затлар тарафыннан кичекмәстән тормышка ашырыла.

Ашыгыч медицина ярдәме дәүләт сәламәтлек саклау системасындагы ашыгыч медицина ярдәменең махсус хезмәте тарафыннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы билгели торган тәртиптә күрсәтелә.

Татарстан Республикасы гражданнарына һәм аның территориясендәге башка затларга ашыгыч медицина ярдәме түләүсез күрсәтелә.

39 статья. Махсуслаштырылган медицина ярдәме

Гражданнарга махсуслаштырылган медицина ярдәме диагностиканың, дәвалауның махсус ысулларын һәм катлаулы медицина технологияләрен файдалануны таләп итә торган чирләр булганда күрсәтелә.

Махсуслаштырылган медицина ярдәме медицина оешмаларында табиб-белгечләр әлеге төр эшчәнлеккә лицензия алган хосусый медицина эшчәнлеге белән шөгыльләнүче затлар тарафыннан күрсәтелә.

Дәүләт сәламәтлек саклау системасы оешмаларында күрсәтелә торган махсуслаштырылган медицина ярдәменең төрләре, күләмнәре

73

һәм сыйфат стандартлары Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

40 статья. Социаль әһәмияткә ия авырулардан интегүче гражданнарга медик-социаль ярдәм

Исемлеге законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә торган социаль әһәмияткә ия авырулардан интегүче гражданнарга медик-социаль ярдәм күрсәтелә һәм тиешле медицина оешмаларында түләүсез яки ташламалы шартларда диспансер күзәтүе тәэмин ителә.

Социаль әһәмияткә ия авырулардан интегүче гражданнарга күрсәтелә торган медик-социаль ярдәм төрләре һәм күләме кызыксынучы министрлыклар һәм ведомстволар белән бергә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

Социаль әһәмияткә ия авырулардан интегүче гражданнарга медик-социаль ярдәм күрсәткәндә бирелә торган ташламалар исемлеге һәм төрләре законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

41 статья. Әйләнә-тирәдәгеләргә куркыныч тудыручы авырулардан интегүче гражданнарга медик-социаль ярдәм

Исемлеге законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә торган, әйләнә-тирәдәгеләргә куркыныч тудыручы авырулардан интегүче гражданнарга медик-социаль ярдәм дәүләт сәламәтлек саклау системасының шул максат өчен билгеләнгән учреждениеләрендә түләүсез күрсәтелә.

Әйләнә-тирәдәгеләргә куркыныч тудыручы авырулардан интегүче гражданнарга күрсәтелә торган медик-социаль ярдәм төрләре һәм күләме кызыксынучы министрлыклар һәм ведомстволар белән бергә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасының Санитария-эпидемиология күзәтүе дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнә.

Әйләнә-тирәдәгеләргә куркыныч тудыручы авырулардан интегүче гражданнарның аерым категорияләре өчен аларның вакытлыча эшкә сәләтсезлеге чорында законнар нигезендә эш урыны, шулай ук башка ташламалы өстенлекләр саклана.

**42 статья.** Профилактиканың, диагностиканың, дәвалауның яңа ысулларын, даруларны, иммунобиологик препаратларны һәм дезинфекцияләү чараларын куллану һәм биомедицина тикшеренүләрен уздыру тәртибе

Сәламәтлек саклау гамәлиятендә кулланылышы закон тарафыннан рөхсәт ителгән профилактика, диагностика, дәвалау ысуллары, медицина технологияләре, дарулар, иммунобиологик препаратлар һәм дезинфекцияләү чаралары кулланыла.

Куллануы рөхсәт ителмәгән, әмма билгеләнгән тәртиптә каралуга тапшырылган диагностика, дәвалау ысуллары һәм дарулар, пациентны дәвалау мәнфәгатьләрендә, бары тик аның үз теләген белдергән язмача ризалыгын алганнан соң гына кулланылырга мөмкин.

Куллануы рөхсәт ителмәгән, әмма билгеләнгән тәртиптә каралуга тапшырылган диагностика, дәвалау ысуллары һәм дарулар 15 яшенә җитмәгән затларны дәвалау өчен бары тик аларның гомерләренә турыдан-туры куркыныч янаганда гына һәм аларның законлы вәкилләренең язмача ризалыгы белән генә кулланылырга мөмкин.

Әлеге статьяның икенче һәм өченче өлешләрендә күрсәтелгән диагностика, дәвалау ысулларын һәм даруларны, иммунобиологик

препаратларны һәм дезинфекция чараларын, шул исәптән чит илләрдә файдаланылучыларны да, куллану тәртибе Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы яисә шуңа вәкаләтле башка органнар тарафыннан билгеләнә.

Биомедицина тикшеренүләрен үткәрү сәламәтлек саклау оешмаларында гына рөхсәт ителә һәм ул алданрак үткәрелгән лаборатория экспериментына нигезләнергә тиеш.

Кешене объект буларак җәлеп итеп, теләсә нинди биомедицина тикшеренүен үткәрү бары тик гражданның язмача ризалыгын алганнан соң гына мөмкин. Граждан биомедицина тикшеренүендә катнашырга мәҗбүр ителә алмый.

Биомедицина тикшеренүенә ризалыгын алганда, гражданга тикшеренүнең максатлары, ысуллары, кырын нәтиҗәләре, куркыныч ихтималы, дәвамлылыгы һәм көтелүче нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирелергә тиеш. Граждан теләсә кайсы стадиядә тикшеренүдә катнашудан баш тартырга хокуклы.

Билгеләнгән тәртиптә тикшерү сынаулары узмаган профилактика, диагностика, дәвалау ысулларын, даруларны пропагандалау, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында да, тыела. Әлеге норманы бозу законда билгеләнгән җаваплылыкка китерә.

43 статья. Халыкны дарулар һәм медицина әйберләре, иммунобиологик препаратлар һәм дезинфекцияләү чаралары белән тәэмин итү

Дарулар һәм медицина әйберләре җитештерү, сатып алу һәм сату дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасының республика бюджеты, җирле бюджетлар, медицина иминләштерүе, бюджеттан тыш фондлар акчалары һәм законнар белән тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән сәламәтлек саклау оешмалары тарафыннан башкарыла.

Дарулар, иммунобиологик препаратлар, дезинфекцияләү әйберләре һәм медицина әйберләре сыйфатын тикшереп тору Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы яисә шуңа вәкаләтле башка министрлыклар, дәүләт комитетлары һәм ведомстволар тарафыннан башкарыла.

Гражданнарга дарулар белән ярдәм итүне, шул исәптән аларны медицина әйберләре белән тәэмин итүне мондый эшчәнлекне гамәлгә ашыру хокукына лицензия алган дәүләт оешмалары да һәм шулай ук хосусый оешмалар да башкара ала.

Дарулар һәм индивидуаль кулланылышлы медицина әйберләре белән ташламалы шартларда тәэмин ителүдән файдаланучы гражданнар категорияләре Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан законнар нигезендә билгеләнә.

Ташламалы шартларда дару белән тәэмин ителү өчен гражданнарга рецептлар язып бирү хокукына сәламәтлек саклауның дәүләт һәм хосусый системаларындагы дәвалаучы табиблар бертигез дәрәҗәдә ия булалар.

44 статья. Эвтаназияне тыю

Медицина персоналына эвтаназияне тормышка ашыру - нинди дә булса гамәлләр һәм чаралар белән, шул исәптән ясалма чаралар белән, авыруның гомерен саклап торуны туктату юлы белән аның үлемен тизләтү турындагы үтенечен канәгатьләндерү тыела.

Авыруны анлы рәвештә эвтаназиягә этәрүче һәм (яисә) эвтаназияне тормышка ашыручы зат закон нигезендә җаваплылыкка тартыла.

45 статья. Кешенең үлгән мизгелен билгеләү

Үлемне констатацияләү медицина хезмәткәре (табиб яисә фельдшер) тарафыннан башкарыла.

Кешенең үлгән мизгелен билгеләү критерийлары һәм тәртибе, реанимация гамәлләрен туктату законнар нигезендә билгеләнә.

<u>46 статья.</u> Кеше органнарын һәм (яисә) тукымаларын трансплантацияләү өчен алу

Кеше органнарын һәм (яисә) тукымаларын трансплантацияләү өчен алу закон нигезендә рөхсәт ителә.

Кеше органнары һәм (яисә) тукымалары сатып алу, сату предметы һәм коммерция алыш-бирешләре предметы була алмыйлар.

Кеше органнарын һәм (яисә) тукымаларын трансплантацияләү өчен алырга мәҗбүр итү рөхсәт ителми.

Әлеге коммерция алыш-бирешләрендә, кеше органнары һәм (яисә) тукымалары сатып алуда һәм сатуда катнашучы затлар закон нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

<u>47 статья.</u> Патология-анатомия ярулары үткәрү

Патология-анатомия ярулары үлемнең сәбәбе, диагностиканың һәм дәвалауның дөреслеге турындагы белешмәләр алу максатында табиб-белгечләр тарафыннан үткәрелә. Патология-анатомия ярулары үткәрү тәртибе законнар белән билгеләнә. Диагнозның һәм дәвалауның төгәллегенә нинди дә булса шик булмаганда һәм бары тик медицина оешмасы житәкчесенең язмача рөхсәте белән генә патология-анатомия яруларыннан баш тартырга мөмкин. Көч кулланып үтерү турында берәр төрле шик булганда, патология-анатомия ярулары суд-медицина экспертлары тарафыннан үткәрелә.

Үлемнең сәбәбе һәм авыруның диагнозы турында бәяләмә — гаилә әгъзаларына, алар булмаганда — якын туганнарына яисә мәрхүмнең законлы вәкиленә, шулай ук хокук саклау органнарына алар таләбе буенча бирелә.

Мәрхүмнең гаилә әгъзаларына, якын туганнарына яисә законлы вәкиленә тиешле юнәлештәге белгечне патология-анатомия яруларында үз ризалыгы белән катнашу өчен чакырту хокукы бирелә.

Мәрхүмнең гаилә әгъзалары, якын туганнары яисә законлы вәкиле таләбе буенча әлеге Законның 51 статьясында каралган тәртиптә бәйсез медицина экспертизасы үткәрелергә мөмкин.

## IX бүлек. Медицина экспертизасы

### <u>48 статья.</u> Хезмәткә вакытлыча сәләтсезлекне экспертизалау

Авырып китү, имгәнү, йөклелек, бала табу, гаиләнең авыру әгъзасын карау, протезлану, шифаханә-курортта дәвалану сәбәпле һәм башка очракларда гражданнарның хезмәткә вакытлыча сәләтсезлеген экспертизалау законнарда билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

Хезмәткә вакытлыча сәләтсезлекне экспертизалауны сәламәтлек саклауның дәүләт һәм хосусый системалары табиблары үткәрә, алар гражданнарга хезмәткә сәләтсезлек кәгазен 30 көнгә кадәр үзләре генә бирәләр, озаграк вакытка хезмәткә сәләтсезлек кәгазе медицина оешмасы җитәкчесе билгеләп куя торган табиблар комиссиясе тарафыннан бирелә.

Хезмәткә вакытлыча сәләтсезлекне экспертизалаганда хезмәткәрне сәламәтлеге буенча вакытлыча яисә даими эшләү өчен башка эшкә күчерү зарурлыгы һәм вакыты билгеләнә, шулай ук гражданнарны тиешле тәртиптә, шул исәптән бу гражданның инвалидлык билгеләре булганда, медик-социаль эксперт комиссиясенә җибәрү турында карар кабул ителә.

Хезмәткә вакытлыча сәләтсезлек кәгазен тутырганда, табиб серен саклау максатында, авыру диагнозы турында мәгълүматлар кертелми, хезмәткә сәләтсезлекнең сәбәпләре (авыру, имгәнү яисә башка сәбәп) генә күрсәтелә.

Аерым очракларда сәламәтлек саклау идарәсенең жирле органнары карары буенча гражданнарның хезмәткә вакытлыча сәләтсезлеген экспертизалау дәүләт сәламәтлек саклау системасы учреждениеләрендә урта медицина белеме булган хезмәткәргә дә йөкләнергә мөмкин.

49 статья. Медик-социаль экспертиза

Медик-социаль экспертиза инвалидлыкның сәбәбен һәм төркемен, гражданнарның эшкә сәләтен югалту дәрәҗәсен билгели, аларны реабилитацияләү төрләрен, күләмен, вакытларын һәм социаль яклау чараларын билгели, гражданнарны эшкә урнаштыру буенча тәкъдимнәр бирә. Медик-социаль экспертиза халыкны социаль яклау системасының медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан башкарыла.

Медик-социаль экспертизаның гражданнарны эшкә урнаштыру буенча тәкъдимнәре, милек рәвешләренә карамастан, оешмаларның администрацияләре үтәү өчен мәжбүри була.

Медик-социаль экспертизаны оештыру һәм үткәрү тәртибе законнар белән билгеләнә.

Граждан яисә аның законлы вәкиле, гариза биреп, теләсә кайсы белгечне медик-социаль экспертиза үткәрүдә катнашу өчен белгеч ризалыгы буенча чакыртырга хокуклы.

Медик-социаль экспертиза үткәргән учреждение бәяләмәсенә карата граждан үзе яисә аның законлы вәкиле законда билгеләнгән тәртиптә судка шикаять белдерә ала.

50 статья. Суд-медицина һәм суд-психиатр экспертизасы

Суд-медицина экспертизасы алдан сорап белешү үткәргән затның, тикшерүченең, прокурорның карары яисә суд билгеләмәсе

нигезендә дәүләт сәламәтлек саклау системасы учреждениеләрендә суд-медицина экспертизасы бюросы эксперты, ә ул булмаганда - экспертиза үткәрүгә җәлеп ителгән табиб тарафыннан үткәрелә.

Суд-психиатр экспертизасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының шул максат өчен билгеләнгән учреждениеләрендә үткәрелә.

Граждан яисә аның законлы вәкиле суд-медицина яисә суд-психиатр экспертизасын билгеләгән органга тиешле юнәлештәге өстәмә белгечне эксперт комиссиясе составына белгеч ризалыгы буенча кертү турында үтенеч юлларга хокуклы.

Суд-медицина һәм суд-психиатр экспертизаларын оештыру һәм үткәрү тәртибе законнар белән билгеләнә.

Суд-медицина һәм суд-психиатр экспертизасы үткәргән учреждениеләрнен бәяләмәсенә карата законда билгеләнгән тәртиптә судка шикаять белдерелә ала.

<u>51 статья.</u> Бәйсез медицина экспертизасы

Гражданнар медицина экспертизасы нәтиҗәләре белән килешмәгәндә, алар үтенече буенча закон нигезендә тиешле төрдәге бәйсез медицина экспертизасы үткәрелә.

Әгәр экспертизаны үткәрүче эксперт йә комиссия әгъзалары медицина экспертизасы үткәргән учреждениедән яисә комиссиядән, шулай ук бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән кызыксынучы органнардан, учреждениеләрдән, урындагы затлардан һәм гражданнардан хезмәте буенча яисә башкача бәйсез булса, экспертиза бәйсез дип таныла.

Бәйсез медицина экспертизасы үткәргәндә гражданнарга эксперт оешмасын һәм экспертларны сайлап алу хокукы бирелә.

Бәхәсле очракларда медицина экспертизасы нәтиҗәсе буенча соңгы карар суд тарафыннан чыгарыла.

## X бүлек. Медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренең хокуклары һәм аларны социаль яклау

52 статья. Медицина һәм фармацевтика эшчәнлеге белән шөгыльләнү хокукы

Татарстан Республикасында медицина һәм фармацевтика эшчәнлеге белән шөгыльләнү хокукына медицина һәм фармацевтика буенча югары һәм урта белем учреждениеләрен тәмамлаган, тиешле белем турында дипломы, белгеч сертификаты һәм лицензиясе булган затлар ия булалар.

Белгеч сертификаты югары уку йортыннан соң һөнәри белем (аспирантура, ординатура) яисә өстәмә белем (квалификациясен күтәрү, специальләшү) яки сайланган белгечлекнең теориясе һәм практикасы буенча, гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге законнар мәсьәләләре буенча медицина һәм фармацевтиканың иҗтимагый берләшмәләре комиссияләре үткәрүче тикшерү сынавы нигезендә бирелә.

Табиблар сәламәтлек саклау оешмаларында укыган чорда аларның һөнәри әзерлеге өчен җаваплы булган медицина персоналы күзәтүе астында әлеге оешмаларда эшләргә хокуклы булалар.

Югары һәм урта медицина белеме бирү учреждениеләре студентларына гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә катнашу өчен рөхсәт укыту программасы нигезендә, аларның һөнәри әзерлеге өчен җаваплы медицина персоналы күзәтүе астында, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы билгели торган тәртиптә законнар нигезендә бирелә.

Тәмамланган югары медицина яисә фармацевтика белеме булмаган затларга урта медицина белемле хезмәткәрләр урыннарында медицина яисә фармацевтика эшчәнлеге белән шөгыльләнү Татарстан

## X бүлек. Медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренең хокуклары һәм аларны социаль яклау

### 52 статья. Медицина һәм фармацевтика эшчәнлеге белән шөгыльләнү хокукы

Татарстан Республикасында медицина һәм фармацевтика эшчәнлеге белән шөгыльләнү хокукына медицина һәм фармацевтика буенча югары һәм урта белем учреждениеләрен тәмамлаган, тиешле белем турында дипломы, белгеч сертификаты һәм лицензиясе булган затлар ия булалар.

Белгеч сертификаты югары уку йортыннан соң һөнәри белем (аспирантура, ординатура) яисә өстәмә белем (квалификациясен күтәрү, специальләшү) яки сайланган белгечлекнең теориясе һәм практикасы буенча, гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге законнар мәсьәләләре буенча медицина һәм фармацевтиканың иҗтимагый берләшмәләре комиссияләре үткәрүче тикшерү сынавы нигезендә бирелә.

Табиблар сәламәтлек саклау оешмаларында укыган чорда аларның һөнәри әзерлеге өчен җаваплы булган медицина персоналы күзәтүе астында әлеге оешмаларда эшләргә хокуклы булалар.

Югары һәм урта медицина белеме бирү учреждениеләре студентларына гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә катнашу өчен рөхсәт укыту программасы нигезендә, аларның һөнәри әзерлеге өчен җаваплы медицина персоналы күзәтүе астында, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы билгели торган тәртиптә законнар нигезендә бирелә.

Тәмамланган югары медицина яисә фармацевтика белеме булмаган затларга урта медицина белемле хезмәткәрләр урыннарында медицина яисә фармацевтика эшчәнлеге белән шөгыльләнү Татарстан

Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә рөхсәт ителә.

Үз белгечлекләре буенча биш елдан артык эшләмәгән табибларга һәм провизорларга практик медицина һәм фармацевтика эшчәнлеге белән шөгыльләнү өчен рөхсәт тиешле мәгариф учреждениеләрендә янадан әзерлек үткәннән соң яисә медицина һәм фармацевтиканың иҗтимагый берләшмәләре комиссияләре үткәргән тикшерү сынавы нигезендә бирелергә мөмкин.

Үз белгечлекләре буенча биш елдан артык эшләмәгән медицина яисә фармацевтика буенча урта белемле хезмәткәрләргә практик медицина яисә фармацевтика эшчәнлеге белән шөгыльләнү өчен рөхсәт үз квалификациясен дәүләт сәламәтлек саклау системасының тиешле учреждениеләрендә раслаганнан соң йә медицина һәм фармацевтиканың иҗтимагый берләшмәләре комиссияләре тарафыннан үткәрелгән тикшерү сынавы нигезендә бирелергә мөмкин.

Чит дәүләтләрдә медицина һәм фармацевтика әзерлеге алган затларга медицина яисә фармацевтика эшчәнлегенә рөхсәт, әгәр халыкара килешүләрдә башкасы каралмаган булса, Татарстан Республикасының яисә Россия Федерациясенең тиешле мәгариф учреждениеләрендә имтихан биргәннән соң, белгеч сертификаты һәм аерым төр эшчәнлек белән шөгыльләнергә лицензия алганнан соң законнар нигезендә бирелә.

Медицина һәм фармацевтика эшчәнлеге белән законсыз шөгыльләнүче затлар закон нигезендә җаваплы булалар.

<u>53 статья.</u> Хосусый медицина эшчәнлеге белән шөгыльләнү хокукы

Хосусый медицина эшчәнлеге — гражданнарның һәм оешмаларның үз акчалары исәбеннән дәүләт сәламәтлек саклау

системасы оешмаларыннан читтә медицина хезмәткәрләре тарафыннан медицина хезмәте күрсәтү ул.

Хосусый медицина эшчәнлеге әлеге Закон һәм башка норматив-хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Югары яисә урта медицина белеме турында дипломы, белгеч сертификаты һәм сайланган эшчәнлек төренә лицензиясе булган затлар хосусый медицина эшчәнлеге белән шөгыльләнү хокукына ия булалар.

Медицина ярдәме күрсәтүнең сыйфатын тикшереп торуны медицина буенча иҗтимагый берләшмәләр һәм җирле администрация гамәлгә ашыра. Хосусый медицина эшчәнлеге белән шөгыльләнүче затлар эшчәнлегенә җирле администрациянең башкача катнашуы, законда турыдан-туры каралган очраклардан тыш, рөхсәт ителми.

Хосусый медицина эшчәнлеге белән шөгыльләнүне тыю хосусый медицина эшчәнлеге белән шөгыльләнүгә лицензия биргән орган яисә суд карары буенча башкарыла.

54 статья. Халык медицинасы белән (сихәтләү белән) шөгыльләнү хокукы

Әлеге Законга карата халык медицинасы — кешеләрнең берничә буыны тәҗрибәсенә нигезләнгән, халыкның гореф-гадәтләрендә урын алган һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлмәгән савыктыру, профилактика, диагностика, дәвалау һәм реабилитацияләү ысуллары җыелмасы ул.

Медицина белеме турында дипломы булган һәм әлеге төр эшчәнлеккә лицензия алган Татарстан Республикасы гражданнары халык медицинасы белән шөгыльләнү хокукына ия булалар.

Законсыз рәвештә халык медицинасы белән шөгыльләнүче затлар закон нигезендә җаваплы булалар.

55 статья. Дәвалаучы табиб

Дәвалаучы табиб — пациентны амбулатор-поликлиник учреждениесендә яисә башка медицина оешмасында күзәтү һәм дәвалау чорында аңа медицина ярдәме күрсәтүче табиб ул. Югары медицина белеме учреждениесендә яисә югары уку йортыннан соңгы һөнәри белем учреждениесендә белем ала торган табиб дәвалаучы табиб була алмый.

Дәвалаучы табиб пациент яисә медицина оешмасы (аның бүлекчәсе) җитәкчесе сайлап алуы юлы белән билгеләнә. Пациент дәвалаучы табибны алмаштыруны таләп иткәндә, дәвалаучы табиб башка табиб сайлап алырга ярдәм итәргә тиеш.

Дәвалаучы табиб пациентны үз вакытында һәм квалификацияле тикшерүне һәм дәвалауны оештыра, аның сәламәтлегенең торышы турында мәгълүмат бирә, авыруның яисә аның законлы вәкиленең таләбе буенча консультантлар чакыра һәм консилиум оештыра. Консультантларның тәкъдимнәре дәвалаучы табиб белән килешеп кенә гамәлгә ашырыла, авыру кешенең гомеренә янаучы экстрен очраклар моңа керми.

Дәвалаучы табиб 30 көнгә кадәр эшкә сәләтсезлек кәгазен үзе бирә.

Пациент дәвалаучы табибның күрсәтмәләрен яисә медицина оешмасының эчке тәртип кагыйдәләрен үтәмәгән очракларда, тиешле урындагы затлар белән килешеп, әгәр дә пациент гомеренә һәм әйләнә-тирәдәгеләрнең сәламәтлегенә куркыныч янамаса, дәвалаучы табиб пациентны күзәтүдән һәм дәвалаудан баш тарта ала.

Дәвалаучы табиб үзенең һөнәри вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән өчен закон нигезендә җаваплы була.

56 статья. Гаилә табибы

Гаилә табибы — женесенә һәм яшенә карамастан, гаилә әгъзаларына беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтү буенча күпкырлы махсус әзерлек узган табиб ул.

Гаилә табибының эшчәнлек тәртибе Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

57 статья. Табиб анты

Югары медицина белеме учреждениеләрен тәмамлаган һәм табиб дипломы алган затлар табиб анты бирәләр.

Табиб анты тексты билгеләнгән тәртиптә раслана.

Табиб антын бозган өчен табиблар закон нигезендә җаваплы булалар.

58 статья. Табиб сере

Гражданның медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать итүе, аның сәламәтлегенең торышы, чиренең диагнозы һәм аны тикшерүдән, дәвалаудан алынган башка белешмәләр табиб серен тәшкил итәләр. Гражданга бирүче белешмәләрнең конфиденциальлек гарантиясе расланырга тиеш.

Укытканда, һөнәри, хезмәт һәм башка вазыйфаларны үтәгәндә башка затларга мәгълүм булган, табиб серен тәшкил итүче белешмәләрне әлеге статьяның өченче һәм дүртенче өлешләрендә каралган очраклардан тыш, шул затлар тарафыннан фаш итү рөхсәт ителми.

Табиб серен тәшкил иткән белешмәләр пациентны тикшерү һәм дәвалау мәнфәгатьләрендә, фәнни тикшеренүләр үткәрү, фәнни әдәбиятта бастыру өчен, әлеге белешмәләрне уку-укыту барышында

һәм башка максатларда файдалану өчен гражданның яисә аның законлы вәкиленең ризалыгы белән башка гражданнарга, шул исәптән урындагы затларга, бирелергә мөмкин.

Табиб серен тәшкил итүче белешмәләрне түбәндәге очракларда граждан яисә аның законлы вәкиленең ризалыгыннан башка бирү рөхсәт ителә:

1) хәленә күрә үз ихтыярын белдерә алмаган гражданны тикшерү һәм дәвалау максатларында;

2) йогышлы авырулар, күмәк агуланулар һәм зарарланулар таралышы янаганда;

3) суд тикшерүләре һәм тикшеренүләре уздыруга бәйле рәвештә алдан сорашып белү һәм тикшерү органнары, прокурор һәм суд таләбе буенча;

4) 15 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарга ярдәм күрсәткәндә аларның ата-аналарына яисә законлы вәкилләренә хәбәр итү өчен;

5) хокукка каршы гамәлләр аркасында гражданнын сәламәтлегенә зыян килгән дип уйларлык нигезләр булганда.

Табиб серен тәшкил итүче белешмәләрне законда билгеләнгән тәртиптә алган затлар табиб серен ачкан өчен, гражданга китерелгән зыянны исәпкә алып, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре белән бертигез дәрәҗәдә закон нигезендә җаваплы булалар.

**59 статья.** Медицина һәм фармацевтика буенча иҗтимагый берләшмәләр

Медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре закон нигезендә һөнәр берлекләре һәм башка иҗтимагый берләшмәләр төзергә хокуклы.

 

60 статья. Медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләрен социаль һәм хокукый яклау

Медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре түбәндәгеләргә хокуклы:

1) хезмәтне саклау таләпләре нигезендә аларның эшчәнлекләрен, һөнәри вазыйфаларын башкаруга һәм квалификацияләрен күтәрүгә мөмкинлек бирүче тиешле матди-техник шартлар белән тәэмин ителүгә;

2) үзенең һөнәри намусын һәм абруен яклауга;

3) ирешелгән теоретик һәм практик әзерлек дәрәҗәсе нигезендә белгечлек категорияләре алырга;

4) хезмәтенең күләме һәм сыйфаты, белем дәрәҗәсе һәм һөнәри әзерлеге, башкарылучы эшнең катлаулылыгы һәм җаваплылыгы, һөнәри зарарлыгы һәм башка факторлар нигезендә хезмәте өчен түләүгә;

5) һөнәри белемнәрен камилләштерергә;

6) сәламәтлеге буенча һөнәри вазыйфаларны башкару мөмкин булмаганда, Татарстан Республикасының республика бюджеты һәм җирле бюджетлары, сәламәтлек саклауның хосусый системасы оешмалары акчалары исәбеннән яңа һөнәргә өйрәнергә;

7) аның нәтиҗәсендә гражданның гомеренә һәм сәламәтлегенә зарар китерерлек, әмма һөнәри вазыйфаларын саксызлык яисә ваемсызлык белән үтәүгә бәйле булмаган һөнәри хатаны иминләштерергә;

8) граждан сәламәтлегенә куркыныч янаган очракларда оешмаларның яисә гражданнарның элемтә чараларыннан, шулай ук гражданны якындагы медицина оешмасына илтү өчен теләсә кайсы транспорт төреннән тоткарлыксыз һәм түләүсез файдаланырга;

9) законнар нигезендә өстәмә отпуск алырга;

10) закон нигезендә кыскартылган эш вакытына;

11) торакны беренче чиратта алырга, телефон кертергә, мәктәпкәчә балалар бакчаларыннан, шифаханә-курорт учреждениеләреннән балалары өчен урыннар алырга, һөнәри вазыйфаларын юл йөреп башкарганда файдалану өчен ташламалы шартларда автотранспорт алырга.

Авыл җирләрендә һәм шәһәр тибындагы поселокларда эшләүче һәм яшәүче табиблар, провизорлар, дәүләт сәламәтлек саклау системасының урта белемле медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре, шулай ук алар белән яшәүче гаилә әгъзалары законнар нигезендә җылытылган һәм яктыртылган бушлай фатир алырга һәм законнарда каралган башка хокукларга һәм ташламаларга хокуклы.

61 статья. Хезмәт өчен түләү һәм компенсацияләр

Медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренә, шулай ук Татарстан Республикасының югары һәм урта медицина, фармацевтика мәгариф учреждениеләренең фәнни хезмәткәрләренә һәм профессор-мөгаллимнәр составына хезмәт өчен түләү аларның хезмәт шартнамәсендә (контрактында) каралган белгечлекләре, стажы һәм үти торган вазыйфалары нигезендә башкарыла.

Медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре зарарлы, авыр һәм куркыныч хезмәт шартлары өчен хезмәт хакларына процентларда компенсация түләүләре, шулай ук законнарда каралган башка ташламалар алырга хокуклы.

Хезмәт хакын арттыруга, хезмәт хакына өстәмәләргә һәм өстәп түләүләргә, шулай ук башка төрле компенсацияләргә һәм ташламаларга хокуклы хезмәткәрләр категорияләренең исемлеге, Татарстан Республикасының Һөнәр берлекләре федерациясе белән килешенеп, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Дәүләт сәламәтлек саклау системасының фәнни хезмәткәрләренә, шулай ук югары һәм урта медицина, фармацевтика мәгариф учреждениеләренең профессор-мөгаллимнәр составына компенсацияләр түләү, ташламалар бирү тәртибе һәм шартлары медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренә компенсацияләр түләү һәм ташламалар бирү тәртибенә, шартларына туры килә.

Дәүләт сәламәтлек саклау системасынын, эшләре гомерләренә һәм сәламәтлекләренә куркыныч янауга бәйле медицина, фармацевтика һәм башка хезмәткәрләре өчен законнар нигезендә дәүләт мәҗбүри шәхси иминләштерүе билгеләнә.

Кеше иммунитеты дефициты вирусы (ВИЧ) йоктырганнарны диагнозлау һәм дәвалау эшен башкаручы дәүләт сәламәтлек саклау оешмалары хезмәткәрләре, шулай ук эшләре кеше иммунитеты дефициты вирусы материалларына бәйле затлар, үзләренең хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә кеше иммунитеты дефициты вирусын йоктырган очракта, бер тапкыр бирелә торган дәүләт пособиесен закон нигезендә алырга хокуклы.

Медицина ярдәме күрсәткәндәге хезмәт вазыйфаларын яисә һөнәри бурычларын үтәгәндә яисә фәнни тикшеренүләр үткәргән вакытта һәлак булган дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина хезмәткәрләре гаиләсенә 120 айлык хезмәт хакы күләмендә бер мәртәбә акчалата пособие түләнә.

Татарстан Республикасының югары һәм урта медицина мәгариф учреждениеләрен тәмамлап, юллама буенча авыллардагы медицина учреждениеләренә эшкә килгән белгечләргә, авыл хуҗалыгы мәгариф учреждениеләрен тәмамлаган белгечләргә хуҗалык булдыру өчен билгеләнә торган бер мәртәбә пособие бирү тәртибе һәм шартлары кулланыла.

## XI бүлек. Халыкара хезмәттәшлек

### 62 статья. Гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек

Татарстан Республикасының башка дәүләтләр белән гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге хезмәттәшлеге Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Әгәр халыкара шартнамәдә әлеге Закондагыдан үзгәрәк кагыйдәләр билгеләнгән булса, халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

### 63 статья. Татарстан Республикасы территориясендә сәламәтлек саклау өлкәсендә чит ил оешмаларының һәм уртак оешмаларның эшчәнлеге

Чит ил һәм уртак медицина, фармацевтика оешмалары, чит ил фирмалары һәм компанияләре вәкиллекләренең, шулай ук Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе гражданлыгына ия булмаган, әмма Татарстан Республикасы территориясендә сәламәтлек саклау өлкәсендә эшчәнлек белән шөгыльләнү өчен лицензия алган медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренең эшчәнлеге законнар, халыкара шартнамәләр, килешүләр һәм контрактлар белән җайга салына.

91

## XП бүлек. Гражданнар гомеренә һәм сәламәтлегенә зыян китергән өчен җаваплылык

**64 статья.** Гражданнар гомеренә яисә сәламәтлегенә китерелгән зыянны түләттерү нигезләре

Гражданнар сәламәтлегенә зарар китерелгән очракларда гаепләләр зыян күрүчеләргә аны законда билгеләнгән күләмдә һәм тәртиптә түләргә тиешләр.

**65 статья.** Хокукка каршы гамәлләрдән зыян күргән гражданнарга медицина ярдәме күрсәтү чыгымнарын түләттерү

Хокукка каршы гамәлләрдән зыян күргән гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүгә чыгымнар тоткан дәүләт сәламәтлек саклау системасы оешмалары, иминләштерү оешмалары гражданның сәламәтлегенә зыян китергән өчен җаваплы юридик һәм физик затлардан законда билгеләнгән күләмдә һәм тәртиптә зыянны закон нигезендә кире кайтару (регресс) таләбенә хокуклы.

**66 статья.** Сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын бозган өчен медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренең җаваплылыгы

Гражданнарның сәламәтлек саклау өлкәсендәге хокуклары медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре тарафыннан гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә зыян китерерлек итеп бозылган очракта, зыян закон нигезендә түләттерелә.

Зыянны түләү медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләрен закон нигезендә дисциплинар, административ һәм җинаять җаваплылыгына җәлеп итүдән азат итми.

67 статья. Сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның хокукларын һәм ireген кысучы дәүләт органнары һәм урындагы затлар, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре һәм башка затлар гамәлләренә гражданнарның шикаять белдерү хокукы

Сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнарның әлеге Законда билгеләнгән хокукларын һәм ireген кысучы дәүләт органнарының һәм урындагы затларның, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренең һәм башка затларның гамәлләренә законнар нигезендә югарырак дәүләт органнарына, югарырак урындагы затларга яисә судка шикаять белдерелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 18 июне
N 1659